*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ __________________** **Шифр _____________**
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада КФУ**
**по предмету «Татарский язык»**
**заключительный этап (ответы)**
**2019-2020 учебный год**
**10 класс**

**I. Һәр фразеологик гыйбарәне синоним булырдай сүзтезмә белән алыштырып языгыз. /** Напишите каждый фразеологический оборот, заменив синонимичным словосочетанием. (10 баллов).

1. Ат җене кагылган - ат гашыйгы, ат яратучы, ат белән мавыгучы
2. Бармак аша карау – эшкә салкын карау, эшкә илтифатсыз карау, эшне әһәмияткә алмау, эшне игътибарсыз калдыру
3. Дөнья куу – мал җыю, байлык артыннан чабу
4. Зәңгәр хыял – тормыштан аерылган хыял, чынга ашмастай хыял
5. Икмәк төю – икмәкне күп ашау
6. Калай әтәч – мактанырга яратучы, буш кеше, сугышырга яратучы, бәйләнчек кеше
7. Артык күз – чит кеше
8. Беренче адым – башлангыч чор
9. Дүрт куллап – бик теләп, бик рәхәтләнеп эшләү
10. Игътибар үзәгендә - алда торган мәсьәлә, кызыксындырган мәсьәлә, беренче чираттагы эш

**II. Һәр берәмлеккә, бер яңа сүз барлыкка килерлек итеп, бер фонема өстәп языгыз. /** Добавьте к каждому из данных слов одну фонему, чтобы получилось одно новое слово. (10 баллов).
1. Ага – кага, бага
2. Биз – бизү, бизә (бизи)
3. Йомша – йомшак
4. Кич – кичә
5. Мая – маяк
6. Өч – көч
7. Сык – сыкы
8. Тар – утар, атар, тара
9. Уен – куен, буен, туен
10. Шом - шома

**III. Җөмләнең һәр сүзенә морфологик анализ ясап языгыз. /** Сделайте морфологический анализ каждого слова в этом предложении (10 баллов).

*Анаң өчен уч төбендә тәбә куырсаң да, бурычыңны кайтара алмассың.*

Анаң – исем, уртаклык исем, тамыр сүз, баш килештә, берлектә, 1нче зат берлектәге тартым белән төрләнгән, бәйлек белән килгән.
Өчен - бәйлек, баш килешне сораучы бәйлек, анаң сүзе белән янәшә килгән.
Уч - исем, уртаклык исем, *төбе* сүзе белән 2 нче төр изафә бәйләнештә - тезмә сүз, баш килештә, берлектә.

Түбәндә - исем, уртаклык исем, уч сүзе белән тезмә сүз составында, - 2нче төр изафә бәйләнешендә, 3нче зат тартым белән төрләнгән, берлектә, урын-вакыт килешендә.
Тәбә – исем, уртаклык исем, тамыр сүз, баш килештә, берлектә, тартым белән төрләнмәгән.
Куырсаң – фигыль, тамыр сүз, затланышлы, шарт фигыль, 2 зат, берлек санда, йөкләтү юнәлешендә, барлыкта.
Да - кисәкчә, көчәйткеч кисәкчә.
Бурычыңны - исем, уртаклык исем, тамыр сүз, төшем килештә, берлектә, 1нче зат берлектәге тартым белән төрләнгән.
Кайтара - фигыль, затланышлы, хикәя фигыль, тамыр сүз, йөкләтү юнәлешендә, барлыкта, алмассың ярдәмче фигыле белән бергә килгән.
Алмассың – ярдәмче фигыль, хикәя фигыль составында, 2 зат берлек санда, юклыкта.

**IV. Бирелгән җөмләләрне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез. /** Прочитайте приведённые предложения и выполните задания. (10 баллов)

(1) Мең тугыз йөз сиксән алтынчы елның маенда мин Югославиягә бардым. (2) Белградта, кунакханәгә урнашып, тамак ялгап алгач, кичке якта бер дустым белән шәһәр карарга чыктык. (3) Безнең кунакханә тимер юл вокзалы янында иде. (4) Без ерак китмәдек <…> шул тирәдә әйләндек. (5) Берөзлексез каршыга кешеләр уза, үзара нидер сөйләшәләр, ләкин телләрен аңлап булмый.

(6) Кунакханәгә кайттык. (7) Бүлмәгә кереп яткач, мин уйлап куйдым: иле башка, теле ят, гореф-гадәтләре чит. (8) Кинәт кенә Бөек Ватан сугышында немецларга әсир төшкән татар солдатлары күз алдына килде. (9) Исән калганнарының байтагы, туган җирләренә кайтырга куркып, төрле илләргә таралган. (10) Никадәр кыен булгандыр аларга чит-ят җирләрдә тормыш корып җибәрүе.

1. 10 нче җөмләдән баш кисәкләрне табып языгыз.
_____________тормыш корып җибәрүе кыен булгандыр____________________

2. Тиңдәш кисәкләр булган җөмләләрнең номерын языгыз.
__________________________________________4,5_____________________________________
___

3. 7 нче җөмләдә ничә гади җөмлә бар? Җавапны сан белән языгыз.
________________________________________4__________________________________________

4. 4 нче җөмләдә <…> тамгасы урынына кайсы тыныш билгесе куелырга тиеш? Ни өчен?
____________өтер. Китмәдек, әйләндек – тиңдәш кисәкләр. Тиңдәш кисәкләр арасына бары тик өтер генә куела.___________________________________________

5. 7 нче җөмләдәге тыныш билгеләренең куелышын аңлатып языгыз.
___________________________________________________________________________________

**Бүлмәгә кереп яткач, (1) мин уйлап куйдым: (2) иле башка, (3) теле ят, (4) гореф-гадәтләре чит.(5)**
___________________________________________________________________________________
_____1 - Аерымланган вакыт хәле җөмлә башында килгәндә, аннан соң өтер куела.
2 - Баш җөмлә иярчен җөмләдән алда килгәндә, : куела.
3,4 – үзара тезүле бәйләнештәге иярчен җөмләләр арасында өтер куела.
5 – хикәя җөмлә ахырында нокта куела.

**V. Кроссвордларны чишегез.** /Решити кроссворды (20 баллов. За каждое верно угадонное и написанное слово по 1 баллу)

**А) Бирелгән сүзләрнең синонимнарын языгыз./** Напишите синонимы данных слов.

**Ответы**

1. **Әләк – яла**
2. **Афәт - бәла, каза**
3. **Белгеч - оста**
4. **Барлык – барча**
5. **Бүтән - башка**
6. **Алфавит – әлифба**
7. **Дустанә – дусларча**
8. **Механизм – җайланма**
9. **Дуамал - уйламыйча**
10. **Кайвакыт – кайчагында**

**Б) Парлы сүзнең беренче кисәген языгыз. /** Напишите первый компонент парного слова.

**Ответы:**

1. **Кача-поса**
2. **кара-каршы**
3. **кием-салым**
4. **күрше-күлән**
5. **табак-савыт**
6. **калдык-постык**
7. **сый-хөрмәт**
8. **рәхим-шәфкать**
9. **исәпсез-хисапсыз**
10. **тигезле-тигезсез**

**VI. Татар тел белемендә ялгызлык исемнәрен өйрәнү турында языгыз. Җавабыгызны мисаллар белән аңлатыгыз.** / Напишите об изучении имен собственных в татарском языкознании (20 баллов).

Татар теленең сүзлек составында үзенчәлекле семантикага ия булган, барлыкка килү, ясалыш һәм кулланылыш даирәсе һәм мөмкинлекләре ягыннан башка төр берәмлекләрдән аерылып торган сүзләр – ялгызлык исемнәре бар. Әлеге төр берәмлекләрне өйрәнә торган ономастика фәне лексикологиянең бер тармагы булып санала, әмма ул башка тармаклар арасында үзенчәлекле урын били.

Халык тарихы, мәдәнияте, теле, географик урыны һәм хәзерге яшәеш мохите белән бәйле мәгълүматлар ялгызлык исемнәрендә сакланганлыктан, ономастика фәне үз эченә гуманитар белемнәрне дә туплый. Хәзерге тел белемендә әлеге юнәлеш үз урынын тапкан фән буларак кабул ителсә дә, өйрәнелә торган тармакларның күплеге һәм яңадан-яңа мәсьәләләренең барлыкка килүе белән, ул үзенең актуальлеген югалтмый, киресенчә, аның өйрәнү юнәлешләре киңәя бара.

Хәзерге татар теле белемендә ономастика зур үсешкә ирешкән, фәнни мәктәп буларак формалашкан һәм шактый казанышлары булган фән санала. Аның барлыкка килүе һәм интенсив рәвештә үсеше XX гасырның 60 нчы елларына туры килә. Татар ономастика өлкәсендәге беренче системалы фәнни эзләнүләр филология фәннәре докторы, профессор Г.Ф. Саттаров исеме белән бәйле. Татар ономастикасы фәненең формалашуы, аның төрле

тармакларга аерылып үсеп китүе, Казан төрки-татар ономастикасы фәнни мәктәбенең оешуы – барысы да галимнең тынгысыз һәм тырыш эшчәнлегенең нәтиҗәсе булып тора. Хәзерге татар ономастикасы казанышлары – профессор Гомәр Фәез ул Саттаров һәм аның укучыларының дистәләгән еллар дәвамында алып барган хезмәт җимеше.

**VII. Кайбер кешеләр компьютер уеннары чынбарлыктагы тормыштан кызыграк дип уйлый. Сез ничек уйлыйсыз? Сез бу фикер белән килешәсезме? Шуңа мөнәсәбәтегезне белдереп язгыгыз. Язмагыз 80 сүздән ким булмаска тиеш. Фикерегезне дәлилләп, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез.** / Некоторые люди считают, что компьютерные игры лучше чем жизнь. А вы как думаете? Вы согласны? Напишите сочинение (не менее 80 слов), выражая ваше отношение к этому. Приведите не менее 2 довода-примера (20 баллов)

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| *II* | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| *III* | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |